


*Для детей дошкольного возраста*

*Воспитатель: Медведева Альфия Магсумовна;*
*Детский сад №5 с. Буздяк; ноябрь 2020 года.*

*Ноябрь 2020 года*
*с. Буздяк*

# Песни, потешки и пальчиковые игры

## на татарском языке



Потешки и стихи, которые можно использовать при массаже или купании ребенка.

## Бала юындыру йоласы

**Атаң кискән утын түгел**
**Анаң яккан мунча түгел,**
**Аюдай симез бул, бүредәй җитез бул.**
**Аю баласы, бүре баласы, мунча ташы, бүрәнә башы,**
**Картны күрсәң, бабай диген**
**Карчыкны күрсәң, әби диген**
**Яшьне күрсәң, абзый диген, җиңги диген**
**Тәмле телле бул**
**Атаң ташы түгел, мунча ташы**
**Минем кулым түгел, Әйшә-Батман кулы**
**Минем телем түгел**
**Идел кичкән инәләр теле**
**Кәбестәгә су салдым,**
**Суы сарыксын, үзе калыксын.**
**Бүрәнә астыннан куян чыккан –**
**Чоррр иткән...**
**Ят та йокла,тор да уйна.**



## Баланың әнисе коендырганда менә болай әйткән:

***Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Ләәә иләәһә илләллааһү***
***Мүхәммәдүр расүүлүллааәһ.***
***Суы сарыксын, үзе калыксын,***
***Бәхетле- тәүфикълы булсын!***
***Иманлы җаннардан яралган булсын!***
***Әти-әнисенә шәфкатьле булсын, олыга-кечегә***
***мәхәббәтле күренсен.***
***Мичтәй, моржадай таза, дөядәй зур булып үссен!***
***Суы сарыксын, үзе калыксын,***
***Тигез канатлы булсын,***
***Озын гомерле булсын!***
***Җиңел пар белән сине, улым (кызым)!***



## “Чакылт-чокылт”
## массаж ясау өчен мавыктыргыч

Поезд йөри
Чакылт-чокылт,
Чакылт-чокылт,
Чакылт-чокылт!

Тәгәрмәче -
Чакылт-чокылт,
Чакылт-чокылт,
Чакылт-чокылт!

Поезд ишеге
Ачык -
Тәгәрәп төште
Капчык!
Коелды аннан борчак,
Жыелды халык шул чак:

Тавыклар
Кыт-кыт-кытак!
Үрдәкләр
Бак-бак-бак-бак!

Чыпчыклар
Чырык-чырык!
Каргалар
Карык-карык!
Сарыклар
Бәә-бәә!
Кәҗәләр
Мәә-мәә!
Песи генә йоклаган,
Аңа борчак калмаган…

Ә-ә-ә! Берәү калган икән -
Чокырга тәгәрәп киткән!



## Суда уйныйбыз!



Диңгездә йөзә балык.
Сикерә, чума,
Чыга калкып.
Бер балык,
Йөз балык,
Артыннан йөзәм талып.

## "Куянкай"



Куян китап тапты.
Укыды, укыды, япты.
Онытып бетергәч, тагын ачты.
Укыды, укыды, япты.
Яңадан ачты.
Укыды, укыды, япты.
Куян китапны шәп белде.

## Пальчиковые игры на татарском языке
## Бармак уеннары



Бу бармак-бабай,
Бу бармак-әби,
Бу бармак-әти,
Бу бармак-әни,
Бу бармак-нәни бәби,
Аның исеме- чәнти!

***

Баш бармак баш кашый,
Имән бармак имән ташый,
Урта бармак утын яра,
Атсыз бармак ат жигә,
Чәнти бармак чәй эчә.



***

Карга килер — казан асар,
Торна килер — тоз салыр,
Саескан килер — салма салыр,
Песнәк килер — пешерер,
Чыпчык килер — төшерер,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моннан алыр,
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер…
(Чәнти бармагын тотып, баланың уч төбен кытыклыйлар.)

***

Бер — бермәк,
Ике — икмәк,
Дүрт — дүртмәк,
Биш — бишмәт,
Алты — атмак,
Жиде — житмәк,
Сигез — сикмәк,
Тугыз — тукмак,
Ун — уймак,
Таба тулы коймак,
Мә сиңа да бер бармак! (Балага бер бармак тоттыралар)



***

(Баланың кул аркасын
сыйпап.)
Песикәй, песикәй,
Ала мәче сөт эчә,
Кара мәче күз кыса.
Кит дигәндә китмәсәң,
Лапасага чәп итә.
(Алып өлгермәсә,
кул сыртына «чәп» итәләр.)





***

Кылый куян сикерә,
Биек нарат астында
Ә икенче агачта,
Бутән куян сикерә



***

— Монда май бар иде,
май кая китте?
— Песи ашап китте.
— Песи кая китте?
— Салам астына кереп
китте.
— Салам кая китте?
— Сыер ашап китте.
— Сыер кая китте?



— Котүгә китте.
— Тебәй, тебәй, тебәй!
(учны кытыклыйлар)
— Бармак, бармак,
Кайда булдың?
— Бу абый белән
Урманга бардым.
Бу абый белән
Кырда йөгердем.
Бу абый белән
Ботка ашадым.
Бу энем белән
Җыр җырладым.



**Уенчыкларның исемнәрен әйтә-әйтә, балалар бармакларын бөгеп баралар.**

***

Баш бармагым туп була,
Имән бармак — бөтерчек.
Урта бармак була шакмак,
Атсыз бармак — сикергеч.
Чәнти бармак — барабан,
Сана, әйдә, яңадан.





***

Бу бармак — кыяр,
Бусы — кәбестә,
Бу бармак — кишер,
Бусы — чөгендер,
Ә бусы суган булды —
Минә кәрзинем тулды.
(бармакларны йодрыклыйлар)

***

Баш бармак була бүре,
Имән бармагым — төлке,
Урта бармагым — керпе,
Атсыз бармагым — аю,
Чәнти бармагым — куян,
Куянны кая куям?



**Яшелчәләрне истә калдырыр өчен бармак уены.**



***

Бу бармак- кабак,
Бу бармак- борыч,
Бу бармак- кишер,
Бу бармак- кыяр,
Бу бармак- суган.
Яшелчә быел уңган,
Бакчабызда бар да бар!
Шунсы кызык, болар барсы
Кәрзингә ничек сыйган?

***

Бу бармак- чөгендер,
Бу бармак- сарымсак,
Бу бармак- баклажан,
Бу бармак- помидор,
Бу бармак- бәрәңге.
Бик тиз җыеп бетердек,
Ярый әле өлгердек.
Җәйге яңгыр килеште,
Яшелчәләр тиз үсте.





***

**Бу бармак-груша,**
**Бу бармак-чия,**
**Бу бармак-персик,**
**Бу бармак-лимон,**
**Бу бармак-алма.**
**Кайсы үсә бакчада,**
**Кайсы бардыр сатуда.**
**Витаминнарга бик бай,**
**Бик куана кыз, малай.**

***

**Бу бармак-виноград,**
**Бу бармак-ананас,**
**Бу бармак-абрикос,**
**Бу бармак-апельсин,**
**Бу бармак-мандарин.**
**Ашап кына өлгер син!**
**Китергәннәр ерактан,**
**Кышка-язга карамый,**
**җиләк-җимеш яшелчәне**
**Бутап әйтү ярамый!**





## Татарские народные песни

### Колыбельная

***

**Әлли бәлли, бәбкәсе,**
**Кая киткән әнкәсе?**
**Каенлыкка җиләккә**
**Айсылуга бүләккә.**

**Әлли бәлли, бәбкәсе**
**Кая киткән әткәсе?**
**Тимерчегә чиләккә**
**Айсылуга бүләккә.**

**Әлли бәлли, бәбкәсе,**
**Кая киткән әбкәсе?**
**Тегүчегә күлмәккә**
**Айсылуга бүләккә.**

**Әлли бәлли, бәбкәсе,**
**Кая киткән бабасы?**
**Чүлмәкчегә чүлмәккә**
**Айсылуга бүләккә.**

**Әлли бәлли, бәбкәсе,**
**Кая киткән Айсылу?**
**Бер кая да китмәгән,**
**Йоклый икән Айсылу.**

***Перевод:***

**Баю-бай, утеночек,**
**Куда ушла мамочка?**
**В березовый лес**
**за ягодкой для Айсылу.**

**Баю-бай, утеночек,**
**Куда ушел папочка?**
**К кузнецу за ведерком**
**для Айсылу.**

**Баю-бай, утеночек,**
**Куда ушла бабушка?**
**К портному за платьицем**
**для Айсылу.**

**Баю-бай, утеночек,**
**Куда улетел дедушка?**
**К гончару за горшком,**
**Айсылу подарит.**

**Баю-бай, утеночек,**
**Куда Айсылу ушла?**
**Никуда не ушла,**
**Спит, оказывается.**

***

## «Ак куян»



1.Ак куян, йомшак куян
Безгә кунакка килгән.
Койрыгы кыска гына
Колагы җиргә тигән.

2.Әйдәгез, кунакларны,
Кишер белән сыйлыйбыз.
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр
Сикерешеп уйныйбыз.





***

## Гармунчы

И дүдәме, дүдәме,
Гармунчыгыз өйдәме?
Өйдә булса, килсен әле,
Биетеп китсен әле.

Ялындыра, ялындыра,
Ялындыра, килми ул,
Килер иде, уйнар иде,
Бию көен белми ул.

Ялынмыйбыз, ялынмыйбыз,
Ялынмыйбыз килмәсә;
Гармун күтәреп йөрмәсен,
Бию көен белмәсә.

